Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче
Кече Әшнәк авыл гражданнары җыены

**КАРАРЫ**

28 октябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче Кече Әшнәк авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарын төзекләндерү өчен вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- кышын Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авылларында урамнарны карап торуга (кардан чистартуга);

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорты;Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Хөснетдинова Р.Ә.

Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы Хөснетдинова Р.Ә.

СОВЕТ БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634001711 ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ